КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 август

г.Казань

№ 833

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2007 ел, 14 декабрь, 717 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Респуб ликасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2007 ел, 14 декабрь, 717 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 15 февраль, 83 нче; 2008 ел, 25 июнь, 440 нчы; 2008 ел, 21 июль, 518 нче; 2009 ел, 27 февраль, 114 нче; 2010 ел, 11 гыйнвар, 2 нче; 2010 ел, 16 сентябрь, 741 нче; 2011 ел, 26 декабрь, 1067 нче; 2014 ел, 12 апрель, 235 нче; 2014 ел, 17 ноябрь, 883 нче; 2015 ел, 4 февраль, 58 нче; 2015 ел, 6 апрель, 223 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 818 нче; 2016 ел, 31 август, 603 нче; 2017 ел, 7 июнь, 351 нче; 2018 ел, 19 апрель, 266 нчы; 2019 ел, 5 декабрь, 1101 нче, 2021 ел, 11 гыйнвар, 1 нче, 2022 ел, 29 гыйнвар, 68 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составына Минһаҗева Энҗе Энгель кызын - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Дәүләт хезмәте ветераннары советы рәисе урынбасарын кертергә;

Захаров Борис Федорович вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт һәм социаль мөнәсәбәтләр академиясе» югары белем бирү һөнәри берлекләре мәгариф учреждениесенең Казан филиалы директоры киңәшчесе, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәте ветераннары советы рәисе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин